**Фирдәвес БӘШИРОВА,**
*шагыйрә, 1986-1989 елларда «Ләйсән» әдәби иҗат оешмасы җитәкчесе*

# ОЗЫН ГОМЕР ТЕЛИМ

Безнең буынның гомере ике чорга – социализм һәм башлангыч капитализм дәверенә туры килде. Бер чордан икенчесенә күчеш һәр дәвернең уңай һәм җитешсез якларын ачыкларга, җиргә берегеп яшәгән адәм баласының яшәү рәвеше фәкать үзенә генә бәйле икәнен аңларга булышты. Бүгенге көндә егерме бишен тутырган яшьләр белән алардан өлкәнрәкләрнең дөньяга карашларында, яшәү рәвешен күзаллауларында, сүзсез, аерма бик зур.

Социализм дәверенең матур күренешләренең берсе – хөкүмәтнең иҗат берләшмәләренә уңай карашы булды, дисәк, ялгышмабыздыр. Чөнки ул чакларда яшьтән үк һәркем төрле юнәлештә эшләгән түгәрәкләр, клублар, оешмаларның үзе теләгәнен сайлый, мөмкинчелекләрен барлый, шунда канатын ныгытып олы тормыш юлына чыга иде.

Яр Чаллы җирендә үткән гасырның алтмышынчы елларында башланып киткән «КАМАЗ» төзелешенә тирә-як төбәкләрдән агылган яшьләр арасында нинди генә талантлар юк иде. Еллар дәвамында атаклы төзүчеләр, ташчылар белән бер рәттән күпме талантлы рәссамнәр, шагыйрьләр, язучылар үсеп чыкты алар арасыннан, нинди генә оешмалар, клублар барлыкка килмәде. Бөек төзелеш белән бәйләнеп күпме әсәрләр, шигырьләр, җырлар иҗат ителде.

Шушы елларда борын төртеп, үз юлын сайлап өлгергән әдәби чишмә – оешмага көннән-көн ләйсән яңгырыдай саф, яшь көчләр өстәлә торды.

Гаиләбез Башкортостанның Бәләбәй шәһәреннән Яр Чаллыга юлланганда, әдәбият дөньясында байтак кайнаган, язу тәҗрибәсе туплаган булсам да, «Ләйсән» оешмасы тупсасыннан башлап 1978 елда гына атлап кердем. Ф. Дунайның: «Башкортчадан татарчага тәрҗемә итүнең ние бар анын! Ярдәм итәрбез...» – дигәне әле дә истә. Дөрестән дә, күп тә үтмәде, Дунай шигырьләр шәлкемемне «Казан утлары» журналына тәкъдим итте, һәм алар анда басылып та чыкты. Шулай итеп, мин «Ләйсән» дөньясына кереп киттем.

Яшь язучылар рәтеннән төрле-төрле чараларда, әдәби семинарлар, конференцияләр эшендә катнашулар, Әмирхан Еники кебек зур язучылар белән очрашулар, минем өчен генә түгел, гомумән, язучы халык өчен зур белем мәктәбе, дөньяга, тормышка карашның офыкларын киңәйтүгә этәргеч иде. Киләчәктә «Ләйсән» әдәби берләшмәсенең җитәкчесе итеп сайлануыма нигез шушы елларда салынуы шиксез.

1986 елда Яр Чаллыда Татарстан Язучылары берлегенең бүлеге эшли иде инде. Дистәгә якын «чын» язучысы булган бүлекне гаҗәеп җитез, төрле башлангычларга маһир, оста оештыручы язучы Газиз Кашапов җитәкли иде. Шушы бүлек һәм «Ләйсән» оешмасы – ике иҗади берләшмә һәр эшне, һәр чараны киңәшләшеп бергә башкарды, бүлешеп тору булмады. Республика язучылары берлегенең бүлегенә нигез салган, байтак язучылар, шагыйрьләр тәрбияләгән «Ләйсән» бу чорда да көннән-көн ныгый, популярлаша барды. Яр Чаллының ярты миллионга якынайган халкының мәдәни дөньясында балкыган якты йолдызларның берсенә әверелде. Нинди генә чаралар оештырылмады бу елларда! Эшчеләр яшәгән торак йортларда, авыл клубларында, мәктәпләрдә очрашулар, авторларның яңа язылган әсәрләрен тикшерүләр, нәшриятка тәкъдим итүләр, әдәби семинарлар белән беррәттән хәтерләрдә уелып калырлык, фәһемле кичәләр үткәрүләр. Яр Чаллының мәдәният сарайлары, «КАМАЗ» заводлары ике күрше республика: Татарстан һәм Башкортостан язучыларының истәлекле очрашу урыннарына әверелде. Күренекле язучылар Мөсәгыйть Хәбибуллин, Мәдинә Маликова, мәртәбәле Мостай Кәрим, Рафаил Сафиннарның кичәләре генә дә Яр Чаллы төбәгенең шул еллардагы мәдәни дәрәҗәсен күрсәтүче саллы дәлилләр булып тора.

1988 ел Башкортостанның Нефтекама шәһәрендә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре белән истә калды. Яр Чаллы язучылары һәм «Ләйсән»леләр түгәрәк өстәлләр артында сөйләшүләрдә катнаштылар, чыгышлар ясадылар.

«Ләйсән»нең 1987 ел өчен төзелгән эш планында ул елларда ташландык хәлдә булган Идел Болгарстаны башкаласы – Болгарга сәяхәт каралган иде. Сәяхәт итү – ул үзең өчен яңа дөнья ачу, яшәү рәвешен, мәдәниятне чагыштыру, тарихка күз сирпү, иҗат өчен этәргеч дип әйтер идем мин.

Август аеның матур бер көнендә «КАМАЗ»ның генераль директоры урынбасары Я. Ә. Баширов ярдәме белән алынган автобуста бер төркем «Ләйсән»леләр ерак юлга чыкты. Борынгы болгарлар – ата-бабаларыбызның эзләреннән узуы, алар яшәгән мохитны күрү һәр кайсыбыз өчен олы ачыш булгандыр дип уйлыйм. Күз күреме мәйданда таралып яткан нигез ташларын, төрбәләр, җимерек биек манара, кече манараларны тын гына йөреп барлап чыктык. Һәркем тын гына үз уена чумган иде. Соңгарак Иделнең биек ярында, зур манарадан ерак түгел урында, ут яктык һәм йолдызлар гөмбәзе астында тын гына оеган тарихи Болгар җирендә сөйләшеп, шигырьләр укып, җырлашып озак утырдык. Тарих төпкеленә уелган уйлар таркау, фикерләр дә тонык иде ул минутларда, әмма шушы сәяхәт тәэсирендә соңрак туган шигырь, нәсерләрдә бу мизгелләр чагылыш тапкан иде. Борынгы Болгар хисләрне кайнатмаса, әсәрләр дә тумас иде әлбәттә!

Шундый ук сәяхәт 1988 елда Башкортостанның Уфа шәһәренә оештырылды. «Ләйсән»леләр башкорт язучылары белән очраштылар, Салават Юлаев һәйкәлен, Уфаның башка истәлекле урыннарын күреп йөреп кайттылар. Ике республика язучыларының бәйләнеше төрле очрашулар, кичәләр, матбугатта хәбәрләшүләр аша дәвам итте.

Зур күтәренкелек белән үткән «Агыйдел» – «Казан утлары» кичәсе дә шушы дуслыкның бер күренеше. Башкортостан һәм Татарстанның күренекле язучылары Ирек Киньябулатов, Галим Хисамов, Ринат Хәйри, Мөхәммәт Мәһдиев, Газиз Кашапов, Нур Әхмәдиевларның сәхнәдә утырулары бүгенгедәй күз алдында.

1988 елның 16 декабрендә «Ләйсән» әдәби берләшмәсенең 25 еллык юбилеена багышланган кичә дә хәтердә уелып калган. «КАМАЗ» мәдәни сараенда Казаннан килгән язучылар Шаһинур Мостафин, Мәхмүт Хөсәен, Мөдәррис Әгъләм, урындагы хөкүмәт, төрле оешмалар вәкилләренең котлаулары, оешма тарафына күпме мактау сүзләре яңгырады ул көнне!

«Ләйсән» әдәби берләшмәсенең көче – аның халыкчанлыгында. Оешманың җыелышлары, кичәләре сәнгать, шигърият сөючеләрнең һәркеменә ачык булды. Әсәрләрне тикшергәндә дә әңгәмә каләм тирбәтүчеләргә каты бәрелми, аларны артабан язарга өндәп алып барыла, ә инде язарга теләгән һәр кеше үз юлын табарга тырыша иде. Нияз Вәлиев үзенең зур уйларын өч-дүрт юллык шигырьләренә сыйдырырга тырышып япон поэзиясен өйрәнсә, Фирүзә Җамалетдинова хыял, наз диңгезендә йөзә, Мирһади Разов җырлар иҗат итә, Әлфия Ситдыйкова шигърият дөньясының ишеген кыяр-кыймас кына ачып карый иде. Бөек Ватан сугышы ветераны Идрис Рыскужин алдынгы фикерләрен туплап матбугат битләренә тәкъдим иткәндә, Мансур Сафин музей ачу уе белән яна, Вахит Имамов туачак әсәрләре өчен архивларда эшләп материаллар туплый, Галинур Нәбиев, Салават Гатауллиннар лирик шигырьләре өстендә мәш килә, шигъри осталыклары чарланган Сәлимә Шәрипова, Хәниф Хөснуллиннар китапларын бастырып чыгару турында хыялланалар иде.

Татарстан язучылары берлегенең Яр Чаллыдагы бүлегенә нигез салган «Ләйсән» әдәби берләшмәсенең җитәкчесе булып мин эшләгән 1986-1989 елларда алда искә алып киткән исемнәрдән тыш көчле прозаик Альберт Сафин, Әнвәр Шәрипов, Хәниф Хөснуллин, Рәшит Юнысовларның актив эшчәнлеген әйтмичә булмый. Миркадәм Матшин, Венера Хәбибрахманова һәм башкалар автомобильләр чыгарып, йортлар төзеп кенә калмый, матур гаиләләр корып яшиләр, иҗат итәргә дә вакыт табалар иде. Гаҗәеп матур күңелле, күбесе матур тәрбияле иде алар – һәр хәлдә ул еллардагы «Ләйсән»леләр минем

хәтеремдә шулай саклана. Эшләребезне җиңел генә күтәрелеп җитез генә эшли, дәррәү җыйнала, бер-беребезгә ярдәмгә хәзер идек.

Бүгенге «Ләйсән», әлбәттә, тагы да алгарак киткәндер, уңышлары мулрактыр. Аның әгъзаларының күбесе яңа кешеләрдер, яңа гасыр яшьләредер. Әмма моннан 60 ел элек барлыкка килгән бу әдәби оешма бүгенге көнгә исемен, җисемен саклап калган икән, димәк, XXI гасырда да аның кирәге бар. «Ләйсән», аныңише башка әдәби үзәкләр яшәсә, әдәбиятыбызның да киләчәге булыр.

Озын гомер, яңа ачышлар сиңа, «Ләйсән»!

Якты хыяллар, мулдан уңышлар сезгә, «Ләйсән»леләр!

*Казан.*